Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге башкарма комитеты

Надеждино авыл җирлеге Башкарма комитеты
КАРАРЫ

«31» март, 2023 ел № 7

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2020 елның 14 маендагы 267 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Надеждино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында (2021 елның 9 декабрендәге 132, 2022 елның 30 мартындагы 148, 2022 елның 8 декабрендәге 202 номерлы карарларына үзгәрешләр белән)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Надеждино авыл җирлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2023 елның 31 мартындагы 317 номерлы хаты нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2020 елның 14 маендагы 267 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Надеждино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын (2021 елның 9 декабрендәге 132, 2022 елның 30 мартындагы 148, 2022 елның 8 декабрендәге 202 номерлы карарларына үзгәрешләр белән) әзерләргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru), «Вперед» («Алга») район газетасында бастырырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Надеждино авыл җирлеге башлыгы И.З. Галәветдинов